**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Иске Каразирек авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**
Иске Каразирек ав.

№10 31.05.2018 ел

***Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразерик авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»***

2017 елның 5 декабрендәге «Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәләрендәге оешмалар һәм Федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 392-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә,

Иске Каразерик авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразерик авыл җирлеге башкарма комитеты турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы карары белән кабул ителгән нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

3.2 пунктның 13 нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

"- федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство карамагындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрүне контрольдә тоту федераль законнар нигезендә;"

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында» веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: www.yutaza.tatar.ru

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Иске Каразирек авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: Р.М. Мөхәмәдиев